**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Яңа Спас торак пунктында (Яшьләр ур., Үзәк ур., Яңа ур., Заречная ур.) гражданнар җыены карары**

11.11.2020 елы № 1

«Россия Федерация сендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең Яңа Спас торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең Яңа Спас авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (бишйөз) сумм күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәлитү өчен тотарга:

- Мәктәп, Октябрь, Кыр урамнарындагы юллардагы чокырларны ямау;
- торак пункт территориясен чабу;
- Башкарма комитет бинасы янында агачлар кисү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Спас авыл җирлеге
Башлыгы ____________ Н.В.Танчук